**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**муниципального образования**
**«поселок городского типа**
**Актюбинский» Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Губкина, д. 24, п.г.т. Актюбинский,
Азнакаевский муниципальный район,
423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**«Актүбә шәһәр тибындагы поселок»**
**муниципаль берәмлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Губкин урамы, 24 йорт, Актүбә ш.т.п.,
Азнакай муниципаль районы, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» октябрь 2024 ел № 5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 14.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында, карар бирәм:

1. 2024 елның 26 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Каенлы, Радужная, Шатлык урамнары буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен гражданнар җыенын билгеләргә.

Үткәрү урыны: Каенлы урамындагы балалар мәйданчыгы.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе өлешендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез, 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум

күләмендә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә эгъзаларыннан, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән, шулай ук 2 теркем инвалидлар өчен 400 сум күләмендә билгеләп, узара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә коелар урнаштырып, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә коелар урнаштырып, су белән тәэмин итү линияләрен капиталь ремонтлау, урамнарга: Каенлы, Радужная, Шатлык):

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес: http://pravo.tatarstan.ru буенча бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес: http://aznakayevo.tatarstan.ru буенча урнаштырырга кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык А.Л. Севостьянов